ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01.12.2021 Казан ш. № 427-45/тко-2021

«КомунСервис» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә каты коммуналь калдыкларны эшкәртүгә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 18.12.2020 № 577-35/тко-2020 карарында билгеләнгән озак сроклы чик тарифларга 2022 ел өчен төзәтмә кертү хакында

«Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә бәя кую турында» 2016 елның 30 маендагы 484 номерлы карары, Монополиягә каршы федераль хезмәтнең «Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә җайга салынучы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2016 елның 21 ноябрендәге 1638/16 номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә, 2022-2025 елларга каты коммуналь калдыкларны эшкәртүгә озак сроклы чик тарифларны үзгәртү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «2021-2025 елларга «КомунСервис» идарәче компаниясе» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен каты коммуналь калдыкларны эшкәртүгә чик дәрәҗә тарифлар билгеләү турында» 18.12.2020 № 577-35/тко-2020 карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә);

2 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә).

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын вакытлыча башкаручы А.Л.Штром

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
18.12.2020 № 577-35/тко-2020 карарына
(Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
01.12.2021 № 427-45/тко-2021 карары
редакциясендә) 1 нче кушымта

2021 – 2025 елларга «КоммунСервис» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен каты коммуналь калдыкларны эшкәртүгә календарь буенча бүленгән чик тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлек, каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә җайга салынучы эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыручы оешма атамасы | Каты коммуналь калдыкларны эшкәртүгә чик тарифлар, сум/куб.м | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2021 ел | | 2022 ел | | 2023 ел | | 2024 ел | | 2025 ел | |
| | | 1 гыйнвардан | 1 июльдән | 1 гыйнвардан | 1 июльдән | 1 гыйнвардан | 1 июльдән | 1 гыйнвардан | 1 июльдән | 1 гыйнвардан | 1 июльдән |
| | «Яр Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге | | | | | | | | | | |
| 1 | «КомунСервис» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте* | 62,95 | 67,05 | 67,05 | 75,58 | 75,58 | 114,66 | 97,36 | 97,36 | 97,36 | 101,97 |

<*>Салым салуның гадиләштерелгән системасын куллана.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 18.12.2020 № 577-35/тко-2020 карарына (Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 01.12.2021 № 427-45/тко-2021 карары редакциясендә) 2 нче кушымта

«КоммунСервис» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен каты коммуналь калдыкларны эшкәртүгә 2021 – 2025 елларга чик тарифларны җайга салуның озак сроклы параметрлары

| т/с | Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә эшчәнлекнең җайга салынулы төрләрен хәл итүче оешма исеме | Ел | Операция чыгымнарының база дәрәҗәсе | Операция чыгымнарының нәтиҗәлелек индексы | Табышнның норматив дәрәҗәсе | Энергияне саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | электр энергиясенең чагыштырма чыгымы |
| | | | мең сум | % | % | кВт·с/куб.м |
| 1 | «КомунСервис» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | | | | | |
| 1.1 | Каты коммуналь калдыкларны эшкәртү | 2021 | 46 774,36 | 1 | 0 | 0,57 |
| | | 2022 | 52 522,44 | 1 | 0 | 0,57 |
| | | 2023 | 54 077,10 | 1 | 0 | 0,57 |
| | | 2024 | 55 677,79 | 1 | 0 | 0,57 |
| | | 2025 | 57 325,85 | 1 | 0 | 0,57 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге